Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Гаделшә авылы җирлегенең Дүртөйле авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Гаделшә авыл җирлеге составына керүче Дүртөйле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 7 ноябре № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 7 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Гаделшә авыл җирлегенең Дүртөйле авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту)
- зират коймасын төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 233 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 158 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 158 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Гаделшә авыл җирлегенең Дүртөйле авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Гаделшә авыл җирлегенең Дүртөйле авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту)
- Дүртөйле авылы зиратын төзекләндерү (агачларны кисү) буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Гаделшә авыл җирлегенең Дүртөйле авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Гаделшә авыл җирлегенең Дүртөйле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым

кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау (вак таш сатып алу һәм китертү, чокырларны тигезләү, вак таш җәю, грейдерлау, кар чистарту)
- Дүртөйле авылы зиратын төзекләндерү (агачларны кисү).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Гаделшә авыл җирлеге башлыгы ________________ И.А.Нуретдинов